

Бәйрәм турында Татар Лунданыннан Галия Чинакаева сойли.
- Кыр корбаны бәйрәмен безнен әби-бабаларыбыз ихтирам иткән һәм, гадәт буенча, авылыбызда ул ел саен йә май аенда, йә булмаса, жәй башында vтеп килә.
Бәйрәм дога кылу белән башлана, аннары Аллахы Тәгаләдән уныш мул булып vсvне, доньяларда тынычлык булуны, табигатьнен рәхимле булуын сорап, корбан бугазлана.
Гадәт буенча, бу конне ойләребездә, хужалыкта бернинди эшләр vтәлми. Бу бәйрәм алдыннан аксакалларыбыз, әбиләребез оч кон беррәттән авылыбыз яны кырына намаз укырга чыгалар. Оченче конне, намаздан сон, корбан бугазлыйлар. Итеннән, урнашылган гадәт буенча, халыкны сыйлау максаты белән, салма пешерәләр.
Әйтеп китәргә кирәк, Татар Лунданында мулла да, мәчет тә юк, шуна барлык ислам дине елаларын кvрше Кочетовка-Чатока авылы мулласы – Вахит хазрәт Немешев башкара.
Кыр корбанына авылыбызнын яше-карты жыела дисәк тә ялгышмабыз дип уйлыйм.
Авылдашларым шушы олы милли бәйрәмебезне бергә-бергә әзерли, хәтта Мәскәvдә, Питерда яшәvче якташларыбыз да сәдака жибәреп бәйрәмдә читтән торып катнаша.
Бәйрәмебезне хормәт итеп, башка милләт кешеләре дә, оештыру очен, акчаларын биреп киләләр. Шул акчаларга корбан итәр очен сарык алабыз, аннары казаннарда ит, салма пешереп бар кунакларны сыйлыйбыз. Кырга, Кыр корбаны бәйрәменә килә алмаган картларыбызга, аш-суны ойләренә илтеп бирәбез.
Дини таләпләр буенча, корбаннын соякләре белән тиресен жиргә кvмәбез.

*Фото: Диляра Утимишева*